# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы торак пунктта 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2023 елның 23 ноябре** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Күгеш авылы торак пунктында гражданнар җыены **карар кабул итте**:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә булган урам юл челтәрен тоту һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- территорияне пычрактан, чүп-чардан, кардан һәм боздан җыештыру (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, бульдозер җиһазлары (отвал) сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Беларусь тракторын тоту һәм хезмәт күрсәтү (шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- тышкы төзекләндерү объектларын техник паспортлаштыру (поселение урамнарын паспортлаштыру)
- территориянең Тышкы төзекләндерү объектларын ("Чәй суы" чишмәсен) төзү һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формаларын сатып алу, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- торак пункт территориясендә агачларны кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Күгеш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштыру юлы: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1а йорт (СДК бинасы), игълан итәргә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында

(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зеленодольск муниципаль районы,
Күгеш авыл җирлеге башлыгы: А. А. Гатауллин